СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 14 » декабрь 2016 ел** **№ 91**

**Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында**

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 22 гыйнварындагы 313 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Уставына (2015 елның 28 маендагы 335 номерлы, 2015 елның 26 октябрендәге 11 номерлы, 19.02.2016 елгы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:**

« 12) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

**42 статьяга түбәндәге эчтәлекле 18, 19 пунктлар өстәргә:**

«18) район башлыгы әлеге устав нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органын билгели».

19) район башлыгы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органына, проектның нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру һәм Федераль законның 9 статьясындагы 2 - 5 өлешләре нигезендә аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен муниципаль-хосусый партнерлык проектына җибәрә. «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы.

**47 статьяда түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:**

- 47 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

10) муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә районның башкарма комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашырганда, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү хокукына конкурслар уздыру өчен конкурс документациясен гавами партнерга килештерә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыруны мониторинглауны гамәлгә ашыру;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында гавами партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда ярдәм итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып бара;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү хакында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру мониторингы нәтиҗәләрен вәкаләтле органга тапшыра;

- 2015 елның 13 июлендәге Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру. «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы, башка федераль законнар, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм норматив хокукый актлары, әлеге устав һәм муниципаль хокукый актлар белән.

2. Әлеге карарны, ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә, Уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Арча муниципаль районы башлыгына уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән “Арча муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карарны бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

4. Арча муниципаль районы башлыгына уставларны теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) көне турында белешмәләр җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев